РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«5» ноября 2024 ел г. Альметьевск № 3592

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2024 елның 16 сентябрендәге 3041 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында»2024 елның 16 сентябрендәге 3041 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2.1 пунктындагы 2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Әлмәт шәһәре һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы хәрби комиссариатына мөрәҗәгать иткән һәм махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт (алга таба - Контракт) төзегән Россия Федерациясе гражданнарына, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче затлардан тыш, бер мәртәбә бирелә торган түләү бер мәртәбә башкарыла.»;

карарга 1 нче кушымтаның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.2 пунктча өстәргә:

«2.2. Бер мәртәбә түләү 2024 елның 16 сентябреннән 2024 елның 31 декабренә кадәр Контракт төзегән гражданнарга башкарыла.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 16 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

заказ № 1-851

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең хокукый мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Яфизовка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — А.Р. Исхаков